КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 15 декабрь г.Казань № 1627

Татарстан Республикасында вакансияләр һәм укыту эш урыннары ярминкәләрен оештыру тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законының $7^{1-1}$ статьясындагы 1 пунктының 17 пунктчасы һәм «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясындагы 4 өлешенең $10^8$ пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында вакансияләр һәм укыту эш урыннары ярминкәләрен оештыру тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 15 декабрь, 1627 нче
карары белән расланды

# Татарстан Республикасында вакансияләр һәм укыту эш урыннары ярминкәләрен оештыру тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртиптә Татарстан Республикасында вакансияләр һәм укыту эш урыннары ярминкәләрен (алга таба – Вакансияләр ярминкәләре) оештыру һәм уздыру регламентлаштырыла.

1.2. Вакансияләр ярминкәләре Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре) тарафыннан оештырыла. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) Вакансияләр ярминкәсен үткәрү буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең эшчәнлеген координацияләүне һәм контрольдә тотуны тәэмин итә.

1.3. Вакансияләр ярмикәләре хезмәт базарындагы социаль киеренкелекне киметү, гражданнарга яраклы эш эзләүдә булышлык күрсәтү, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнарны эш белән тәэмин итү, оешмаларны кадрлар белән тәэмин итү, хезмәт базары торышы, эшкә урнашу мөмкинлекләре һәм, кирәк булганда, һөнәри сыйфатларны, белгечлекләрне һәм мәнфәгатьләрне экспресс-диагностикалау турында гражданнарга мәгълүмат бирү юлы белән гражданнарның һөнәри үзбилгеләнүгә ихтыяҗларын канәгатьләндерү, эш бирүчеләр тарафыннан вакантлы эш урыннарын күрсәтү һәм эшкә кабул итү мәсьәләләре буенча гражданнарга консультация бирү өчен уңайлы шартлар тудыру, мәгариф оешмалары тарафыннан белем бирү оешмаларына керү тәртибе һәм уку программалары турында мәгълүмат бирү максатларында үткәрелә.

1.4. Вакансияләр ярминкәләрен уздыруның төп бурычлары – гражданнарның төрле милек рәвешләрендәге, кадрлар сайлауда кызыксынучы эш бирүчеләр белән турыдан-туры (онлайн) очрашуы өчен шартлар тудыру, халыкны эшкә урнашу, яңадан укыту мөмкинлекләре турында мәгълүмат белән тәэмин итү, эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда ярдәм күрсәтү, чараларда катнашучыларга профориентация хезмәтләре күрсәтү.

1.5. Вакансияләр ярминкәләре чикләмәгән катнашучылар даирәсенә юнәлтелгән ачык чаралар булып тора, алар шәһәр, районара, махсуслаштырылган, мобиль үзәкләр кулланып күчмә булырга, шулай ук мини-ярминкә, эш бирүче көне, онлайн-ярминкә форматында булырга мөмкин.

1.6. Вакансияләр ярминкәсендә түбәндәгеләр катнаша:

Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар (алга таба – гражданнар);

«Работа в России» дигән мәшгульлек һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә бердәм цифрлы платформада теркәлгән эш бирүчеләр (юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар) (алга таба – эш бирүчеләр) яисә аларның вәкаләтле вәкилләре;

һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары (алга таба – мәгариф оешмалары).

1.7. Гражданнар, эш бирүчеләр, белем бирү оешмалары Вакансияләр ярминкәләрендә берничә тапкыр катнашу хокукына ия.

1.8. Гражданнар, эш бирүчеләр һәм мәгариф оешмалары өчен Вакансияләр ярминкәсендә катнашу – бушлай.

1.9. Вакансияләр ярминкәсендә катнашу өчен эш бирүчеләргә һәм мәгариф оешмаларына, Вакансияләр ярминкәсен уздыру датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, әлеге Тәртипкә кушымтада бирелгән форма буенча Вакансияләр ярминкәсендә катнашу өчен халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә гариза (алга таба – гариза) бирергә кирәк. Эш бирүчеләр гаризада хезмәткәрләргә булган ихтыяҗ, буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) булу турында белешмәләрне күрсәтә.

1.10. Гариза эш бирүче, мәгариф оешмасы тарафыннан  халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә  түбәндәге ысулларның берсе: халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә мөрәҗәгать итү юлы белән яисә федераль почта элемтәсе оемасы аша җибәрү юлы белән бирергә мөмкин.

1.11. Гариза халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан ул кергән (кабул ителгән) көнне эш бирүчеләрнең һәм мәгариф оешмаларның Вакансияләр ярминкәсендә катнашуына гаризаларны теркәү журналында теркәлә.

1.12. Гаризаны кабул итүдән һәм Вакансияләр ярминкәсендә катнашучылар исемлегенә кертүдән баш тарту рөхсәт ителми.

## II. Вакансияләр ярминкәләрен оештыру

2.1. Вакансияләр ярминкәләре халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан расланган Вакансияләр ярминкәсен үткәрү план-графигы нигезендә оештырыла һәм уздырыла. Вакансияләр ярминкәсен уздыру план-графиклары халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштырыла.

2.2. Вакансияләр ярминкәләрен оештыру һәм үткәрү халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре бүлмәләрендә яки гражданнар өчен транспорт белән уңайлы барып җитә мөмкинлеге булган түләүсез файдалану шартларында оешмалар, җирле үзидарә органнары тарафыннан Вакансияләр ярминкәләрен үткәрү өчен бирелә торган, санитария-эпидемиология нормаларына һәм массакүләм чаралар уздыру кагыйдәләренә туры килә торган җиһазландырылган бүлмәдә гамәлгә ашырыла.

Вакансияләр ярминкәләрен үткәрү бүлмәләрендә урындыклар, өстәлләр белән җиһазланган һәм бланклар, мәгълүмат бирү характерындагы тарату материаллары, язу әсбаплары белән тәэмин ителгән документлар тутыру урыннары булырга тиеш.

Вакансияләр ярминкәләрен оештыру түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Вакансияләр ярминкәсен уздыруга әзерләнү;

2) Вакансияләр ярминкәсен уздыру.

2.3. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәген Вакансияләр ярминкәсенә әзерләү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) Вакансияләр ярминкәсен үткәрүнең еллык (кварталлык) план-графигын төзү һәм раслау. Киләсе кварталга Вакансияләр ярминкәсен үткәрү план-графигы Министрлыкка агымдагы кварталның соңгы аендагы 20сенә кадәр тапшырыла;

2) Вакансияләр ярминкәсен уздыру көненә кадәр 20 эш көненнән дә соңга калмыйча, Вакансияләр ярминкәсен уздыру турында боерык чыгару. Боерыкта Вакансияләр ярминкәсен әзерләү һәм уздыру чаралары максатлары, бурычлары һәм чаралар планы билгеләнә;

3) эш бирүчеләр һәм мәгариф оешмалары вәкилләре арасыннан Вакансияләр ярминкәләрендә мөмкин булган катнашучылар исемлеген билгеләү;

4) массакүләм мәгълүмат чараларында (телевидение һәм радио буенча чыгышларны да кертеп), Министрлыкның рәсми сайтында (mtsz.tatarstan.ru), халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында Вакансияләр ярминкәсен уздыру датасы һәм урыны турында мәгълүмат урнаштыру. Мәгълүмат Вакансияләр ярминкәсе үткәрелә башлаганга кадәр 7 календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

5) Вакансияләр ярминкәсен уздыру өчен бүлмә әзерләү (буш эш урыннары исемлеге һәм башка мәгълүмат материаллары (күрсәткечләр, табличкалар), компьютер һәм оештыру техникасы, элемтә чаралары урнаштыру, эш урыннарын әзерләү (чарада катнашучыларны урнаштыру схемасы нигезендә), янгын сүндерү чаралары һәм гадәттән тыш хәлләр турында хәбәр итү җайланмасы булуны тикшерү).

Вакансияләр ярминкәсен әзерләү һәм үткәрү кысаларында халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре:

1) хезмәт базары торышын, Вакансияләр ярминкәсендә катнаша алган гражданнар, эш бирүчеләр, мәгариф оешмалары санын һәм составын анализлый;

2) эш бирүчеләрнең төбәк вакансияләр банкында күрсәтелгән буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалары булганда Вакансияләр ярминкәсендә катнашу өчен эш бирүчеләрне сайлап алуны гамәлгә ашыра;

3) белем бирү оешмасының белем бирү эшчәнлегенә лицензиясе булганда, шулай ук хезмәт базарында таләп ителә торган һөнәрләр (белгечлекләр) буенча һөнәри белем бирүне гамәлгә ашырганда гражданнарның ихтыяҗларын исәпкә алып, Вакансияләр ярминкәсендә катнашу өчен мәгариф оешмаларын сайлап алуны гамәлгә ашыра;

4) Вакансияләр ярминкәсен әзерләүгә һәм уздыруга бәйле чыгымнарны билгели;

5) Мәгълүматны Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (mtsz.tatarstan.ru), халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре бүлмәләрендә, массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыру юлы белән, шулай ук башка ысуллар белән Вакансияләр ярминкәләр үткәрү турында эш бирүчеләргә, мәгариф оешмаларына һәм гражданнарга мәгълүмат бирү;

6) Эш бирүчеләрне, мәгариф оешмалары вәкилләрен теркәүне һәм урнаштыруны тәэмин итеп, Вакансияләр ярминкәләрен уздыра;

7) гражданнар белән эшкә урнаштыру турында алдан бирелгән ышанычнамә нәтиҗәләре турында эш бирүчеләрдән мәгълүмат җыюны гамәлгә ашыра;

8) Вакансияләр ярминкәсен үткәрүгә йомгаклар ясый;

9) гомуми белем бирү оешмаларының 9 нчы һәм 11 нче сыйныф укучыларының гомуми санында Вакансияләр ярминкәсенә килгән гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның өлешен билгели.

2.4. Вакансияләр ярминкәләрен уздыруга чыгымнарны финанслау бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм Министрлык билгеләгән тәртиптә каралган чыгымнарны финанслау күләмнәре чикләрендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2.5. Вакансияләр ярминкәсен үткәргәндә халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белгечләре:

1) гражданнарга шәһәрнең (районның) хезмәт базарындагы вазгыять, һөнәри-квалификация яктылыгында эш көченә ихтыяҗ һәм тәкъдим турында, хезмәт базарында таләп ителә торган һөнәрләр (белгечлекләр) турында, әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү мөмкинлекләре турында, үз эшеңне ачу мөмкинлеге турында, халыкны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү турында, халыкны эш белән тәэмин итү турында Россия Федерациясе законнарында каралган гарантияләр турында мәгълүмат бирә;

2) һөнәрен (белгечлеген), вазыйфасын, эшчәнлек төрен, һөнәри әзерлек һәм квалификация дәрәҗәсен, эш тәҗрибәсен һәм күнекмәләрен, гражданның эшенә карата теләкләрен (вазыйфа, һөнәр (белгечлек), хезмәт хакы, эш вакыты режимы, хезмәт характеры), хезмәт эшчәнлеген башкару өчен эш бирүче таләпләрен исәпкә алып, гражданнарга вакансияләр сайлап алуны һәм бастырып чыгаруны гамәлгә ашыра;

3) гражданнар арасында эшкә урнаштыру мәсьәләләре буенча тарату материалларын таратыла (белешмә мәгълүмат, буклетлар, брошюралар, анкеталар һ.б.).

2.6. Вакансияләр ярминкәсен үткәргән вакытта гражданнар түбәндәгеләргә хокуклы:

1) таләп ителә торган һөнәрләр һәм яңадан белем алу мөмкинлеге турында мәгълүмат алырга;

2) кәгазьдә яисә электрон чыганакта кзыксыну уяткан вакантлы эш урыннары турында мәгълүмат алырга;

3) халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр турында мәгълүмат, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең элемтәгә керү мәгълүматын алырга;

4) үз-үзен презентацияләү күнекмәләрен алырга, резюме төзүдә, эш бирүчеләр белән әңгәмә узуда ярдәм алырга;

5) эшчәнлек өлкәсен сайлап алу максатларында һөнәри юнәлеш бирү тесты нәтиҗәләрен алырга;

6) эшкә урнашу мәсьәләләре буенча бушлай брошюралар, буклетлар, газеталар һәм журналлар алырга;

7) потенциаль эш бирүчеләр белән беренче әңгәмә узарга, шул исәптән дәгъва кылучының анкетасын тутырырга, эш шартлары турында мәгълүмат алырга (хезмәт хакы күләме, социаль гарантияләр, белем алу һәм аны дәвам итү мөмкинлеге, карьера үсеше перспективалары), эш бирүченең элемтәгә керү турында мәгълүматлар алырга;

8) белем бирү оешмасына керү, укыту шартлары, һөнәр (белгечлек) яисә өстәмә белем алу турында мәгълүмат алырга.

2.7. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре белгечләре эш бирүчеләр һәм мәгариф оешмалары вәкилләреннән Вакансияләр ярминкәсен уздыру йомгаклары буенча эшкә урнаштырылган гражданнар турында сораштырулар үткәрә.

## III. Вакансияләр ярминкәсен үткәрү нәтиҗәләре

3.1. Вакансияләр ярминкәсен үткәрү нәтиҗәләре:

1) гражданнар өчен – хезмәт базарында һөнәрләргә ихтыяҗ булу турында мәгълүмат алу; сезонлы эшләрне дә кертеп, региондагы вакансияләр банкы белән танышу; эш шартлары турында мәгълүмат алу (хезмәт хакы күләме, социаль гарантияләр, карьера үсеше перспективалары); һөнәри юнәлеш буенча хезмәт күрсәтүләр; резюме төзүдә ярдәм; хезмәт турында законнар мәсьәләләре буенча консультацияләр алу; эш бирүче белән беренчел әңгәмә узу; эш бирүче белән беренчел әңгәмә узу; мәгариф оешмасына керү, укыту, һөнәр (белгечлек) алу шартлары турында мәгълүмат алу;

2) эш бирүчеләр өчен – үз-үзен презентацияләү; Татарстан Республикасының хезмәт базарында эш көчләрен тәкъдим итү турында мәгълүмат җыю; вакансияләргә гражданнар турында мәгълүмат җыю, аларның һөнәри сыйфатларын бәяләү, беренчел әңгәмәләр уздыру юлы белән вакантлы вазыйфаларга иң туры килә торган дәгъвачыларны сайлап алу мөмкинлеге;

3) мәгариф оешмалары өчен – укырга теләүче гражданнар турында мәгълүмат алу; гражданнарны белем бирү программалары гамәлгә ашырыла торган мәгариф оешмасы турында; мәгариф оешмасына керү шартлары һәм тәртибе турында мәгълүмат белән таныштыру мөмкинлеге бирү.

3.2. Вакансияләр ярминкәсен уздыру йомгаклары буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәге Министрлыкка Министрлык билгеләгән срокта һәм форма буенча Вакансияләр ярминкәсен уздыру турында хисап тапшыра.

Татарстан Республикасында вакансияләр һәм укыту эш урыннары ярминкәләрен оештыру тәртибенә кушымта

Татарстан Республикасында вакансияләр һәм укыту эш урыннары ярминкәсендә катнашуга
ГАРИЗА

_______________________________________________________________
(юридик затның, индивидуаль эшкуарның тулы исеме)
_______________________________________________________________

ИНН/КПП ____________________________________________
Адресы
(урнашу урыны) ____________________________________________
Элемтәгә керү өчен телефон
номеры, факс ____________________________________________
Электрон адрес
почтасы
_______________________________________________

_______________________________________________________________ йөзендә
(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

20__ елның «__»__________ да үткәрергә планлаштырыла торган Татарстан Республикасында вакансияләр һәм укыту эш урыннары ярминкәсендә катнашучылар исемлегенә кертүегезне сорыйм.

ВАКАНСИЯЛӘР (УКЫТУ ЭШ УРЫННАРЫ) ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТЛАР

| Вазыйфа | Вакантлы урыннар (укыту эш урыннары) саны | Уртача айлык хезмәт хакы | Мәшгульлек шартлары (белгечлек) |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында хезмәткәрләргә ихтыяҗ булу, буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) булу турында мәгълүмат урнаштыруга риза

Риза Риза түгел

______________________ ______________________ ______________________
вазыйфа имза имзаны таркатып язу

Татарстан Республикасында вакансияләр һәм укыту эш урыннары ярминкәсенә кагылышлы мәгълүмат материалларында юридик зат (индивидуаль эшкуар) турында мәгълүмат урнаштыруга риза

______________________ ______________________ ______________________
вазыйфасы имза имзаны таркатып язу

М.У. (булганда) 20___ ел, ________________

______________________________